| СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ**
**20.09.2017**

Зеленодольск ш.

**КАРАР**
**№ 227**

«Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең бер генә кеше идарә торган башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә бушлай катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең бер генә кеше идарә торган башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә бушлай катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт алу тәртибе турындагы нигезләмәне кушымтада бирелгәнчә расларга.
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында урнаштырырга .
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, Советы рәисе** **А. В. Тыгин**

Зеленодольск муниципаль районы
Советының 2017 елның 20 сентябрендәге
227 номерлы карарына
кушымта

«Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең бер генә кеше идарә торган башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә бушлай катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт алу тәртибе турындагы

НИГЕЗЛӘМӘ

1. Әлеге «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең бер генә кеше идарә торган башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә бушлай катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт алу тәртибе турындагы нигезләмә (алга таба - Нигезләмә, муниципаль хезмәткәр) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты нигезендә эшләнгән һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан җәмәгать оешмасы, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативы, күчемсез милек милекчеләре ширкәте идарәсендә бушлай катнашуга яллаучы (эш бирүче) вәкиленең (алга таба - муниципаль хезмәткәрләрнең коммерциягә карамаган оешма идарәсендә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт алу процедурасын регламентлаштыра.

2. Муниципаль хезмәткәрләрнең коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуы мәнфәгатьләр конфликтына яисә мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү мөмкинлеген китермәскә тиеш.

3. Яллаучының (эш бирүченең) вәкилен коммерциячел булмаган оешма идарәсендә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт бирү турындагы гариза (алга таба - гариза) язма рәвештә, әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасында каралганча бирелгән формада муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан җирле үзидарә органы җитәкчесе исеменә төзелә.

4. Муниципаль хезмәткәрләр җирле үзидарә органының кадрлар хезмәтенә (кадрлар хезмәте бүлекчәсе, кадрлар эше буенча белгечкә) гариза бирә (алга таба - кадрлар хезмәте).

5. Гаризаны теркәү кадрлар хезмәте тарафыннан коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә (сәяси партиядән тыш) бер генә кеше идарә торган башкарма орган сыйфатында яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүдә бушлай катнашуга рөхсәт алу турында гаризаны теркәү журналына (алга таба - Теркәү журналы) кергән көнне, әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтада бирелгән форма буенча, гамәлгә ашырыла.

Теркәлү журналының битләре кадрлар хезмәте яисә җирле үзидарә органы тарфыннан номерланырга, тегелергә һәм мөһере белән беркетелергә тиеш.

6. Билгеләнгән тәртиптә теркәлгән гаризаның күчермәсе муниципаль хезмәткәргә кадрлар хезмәте тарафыннан кулга бирелә йә, алынуы турында хәбәр итеп, почта аша җибәрелә. Муниципаль хезмәткәргә тапшырылырга тиешле гаризаның күчермәсендә гаризаны теркәү датасы һәм номеры, әлеге гаризаны теркәгән затның фамилиясе, инициаллары һәм вазифасы күрсәтелеп «Гариза теркәлгән» тамга куела.

7. Кадрлар хезмәте муниципаль хезмәткәрнең коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуы очрагында мәнфәгатьләр конфликты булу яки мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү мөмкинлеге турында килгән гаризаны карый һәм дәлилләнгән бәяләмә әзерли.

8. Коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә муниципаль хезмәткәр катнашында мәнфәгатьләр конфликты ачыкланган яки мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү мөмкинлеге булган очракта, кадрлар хезмәте муниципаль хезмәткәрнең гаризасын канәгатьләндерүдән баш тарту турындагы тәкъдимне дәлилләнгән бәяләмәдә күрсәтә.

9. Муниципаль хезмәткәрнең гаризасы һәм дәлилләнгән бәяләмәсе, гариза теркәлгән көннән алып биш эш көне эчендә, җирле үзидарә органы җитәкчесенә кадрлар хезмәте тарафыннан җибәрелә.

10. Җирле үзидарә органы җитәкчесе гаризаны карау нәтиҗәләре буенча биш эш көне эчендә түбәндәге карарларның берсен чыгара:

муниципаль хезмәткәрнең гаризасын канәгатьләндерә;

әлеге Нигезләмәнең 8 пунктында күрсәтелгән кадрлар хезмәте бәяләмәсендә бәян ителгән нигезләр булганда, муниципаль хезмәткәрнең гаризасын канәгатьләндерүдән баш тарта.

11. Кадрлар хезмәте, җирле үзидарә органы җитәкчесе карар кабул иткәннән соң, ике эш көне эчендә гаризаны карау нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәткәргә кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

12. Гаризанытәге төп нөсхәсе һәм аны карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карарның күчермәсе муниципаль хезмәткәрнең шәхсинамәсенә(личное делога) теркәлә.

«Зеленодольск
муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә
муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы
(эш бирүче) вәкиленең бер генә кеше идарә
торган башкарма орган сыйфатында
коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси
партиядән тыш) белән идарә итүдә бушлай
катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә
органнары составына керугә рөхсәт алу тәртибе
турындагы нигезләмәгә
1 нче кушымта

____________________________________________________
(җирле үзидарә органы җитәкчесе вазифасы, Ф.И.Ат.и.)

__________________________________
_____________________ _
(муниципаль учреждение атамасы)

__________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

__________________________________
(контакт мәгълүматлары)

Бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) идарәсендә бушлай катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүенә рөхсәт бирү турында
гариза

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты нигезендә миңа бер генә кеше идарә итә  торган башкарма орган сыйфатында коммерция эшчәнлеге алып бармаган оешма идарәсендә бушлай катнашуны, идарәнең коллегиаль органы составына керүне (кирәклесен сызарга) рөхсәт итүегезне сорыйм.

____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________.

*( муниципаль хезмәткәр башкарырга ниятләгән эшчәнлек турында мәгълүматны, тиешле эшчәнлекне башкаруның фаразланган башлану датасын, кем буларак, коммерцияле булмаган оешманы күрсәтү, башкасы).).*

______________________ ____________________
(дата) (имза)

«Зеленодольск
муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә
муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы
(эш бирүче) вәкиленең бер генә кеше идарә
торган башкарма орган сыйфатында
коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси
партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез
нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль
идарә органнары составына керугә рөхсәт алу
тәртибе турындагы нигезләмәгә

2 нче кушымта

## Бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) идарәсендә бушлай катнашуга рөхсәт бирү турындагы гаризаларны теркәү журналы яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керү

| № т/б | Гаризаны тапшырган муниципаль хезмәткәрнең Ф.И.Ат.и. | Гариза тапшырган муниципаль хезмәткәр вазыйфасы | Кадрлар хезмәтенә гариза керү датасы (кадрлар хезмәте бүлекчәсе, кадрлар эше буенча белгеч) | Гаризаны кабул иткән муниципаль хезмәткәрнең Ф.И.Ат. и. | Гаризаны кабул иткән муниципаль хезмәткәрнең имзасы | Гаризаның күчермәсен алганда муниципаль хезмәткәрнең имзасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |

Документ электрон формада булдырылган. № 01-01-05-227, 20.09.2017 Башкаручы: 6 Садыйкова
Л.Н.5 Бит булдырылган: 21.09.2017 16:57
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН